**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№12039**
**12.12.2023**

Яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клублары командалары арасында «Белые медведи» хоккей командасы тренеры Морозов О.Ю. истәлегенә багышланган «Белые медведи» клубы призына хоккей буенча XXIV турнир оештыру һәм үткәрү турында

Башкарма комитетның 2022 елның 3 октябрендәге 5186 номерлы карары белән расланган «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә яшьләр сәясәтен үстерү» муниципаль программасын үтәү йөзеннән, массакүләм спорт төрләрен үстерү максатында

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсенә 2023 елның декабрендә яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клублары командалары арасында «Белые медведи» хоккей командасы тренеры Морозов О.Ю. истәлегенә багышланган «Белые медведи» клубы призына хоккей буенча XXIV турнир (алга таба – турнир) үткәрергә.

2. Расларга:

1) турнир үткәрү турында нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) турнирны әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты составын, 1 нче кушымтада каралганча.

3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә турнирны оештыру һәм үткәрү чыгымнарын финанслауны 2023 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетының «Яшьләр сәясәте» 07.07 бүлеге (бүлекчәсе) буенча каралган акчалар хисабына 43 640 (кырык өч мең алты йөз кырык) сум күләмендә финанслауны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2023 елның 12 декабрендәге
12039 номерлы карарына
1 нче кушымта

Яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клублары
командалары арасында «Белые медведи» хоккей командасы
тренеры Морозов О.Ю. истәлегенә багышланган
«Белые медведи» клубы призына хоккей буенча
XXIV турнир үткәрү турында нигезләмә

## 1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. «Белые медведи» хоккей командасы тренеры Морозов О.Ю. истәлегенә багышланган «Белые медведи» клубы призына хоккей буенча XXIV турнир (алга таба – турнир) «Яшүсмер» яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клублары үзәге» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан үткәрелә. Турыдан-туры үткәрү, составы Башкарма комитет карары белән раслана торган оештыру комитетына йөкләнә.

## 2 бүлек. Максатлар

2. Турнир түбәндәге максатларда үткәрелә:
1) сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау;
2) балалар һәм яшүсмерләр сәламәтлеген ныгыту;
3) үсеп килүче буынны даими рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итү.

## 3 бүлек. Турнирда катнашучылар

3. Турнирда Яр Чаллы шәһәре яшьләр клубларының спорт командаларында тәрбияләнүчеләр катнаша.

## 4 бүлек. Үткәрү урыны һәм сроклары

4. Турнир 2023 елның 26 декабреннән 29 декабренә кадәр «Чайка» яшьләр клубының хоккей кортында турнир уеннары календаре нигезендә үткәрелә.

## 5 бүлек. Турнирны үткәрү шартлары

5. Турнир бер тапкыр уйнау юлы белән үткәрелә. Уен төп вакытта бер як та отмаган нәтиҗә белән тәмамланган очракта, 5 минут 4х4 овертайм уйнала. Овертаймда бер як та отмаган нәтиҗә булган очракта, командалар, Россия Федерациясе хоккей уенының әлеге кагыйдәләре нигезендә, 5 буллит сугалар. Төркемдә 1 нче, 2 нче урынны алган командалар турнир җиңүчесен үзара очрашу вакытында билгелиләр. Төркемдә 3, 4 нче урыннарны алган командалар үзара 3 нче урын өчен уйныйлар.

6. Турнир бөтенроссия хоккей уйннары кагыйдәләре буенча үткәрелә – гомуми режимлы 20 шәр минутлык 3 период. Периодлар арасында тәнәфес 5 минут.

## 6 бүлек. Заявка

7. Турнирда катнашу өчен һәр команда, әлеге нигезләмәгә кушымтада каралган форма буенча 2 нөсхәдә, катнашуга заявка бирергә тиеш. Катнашуга заявка табиб тарафыннан таныкланырга һәм һәр уенчы өчен уеннарга кертелү турында табиб визасы булырга тиеш. Команданы комплектлауның дөреслеге өчен персональ җаваплылык команданы тәкъдим итүче җитәкчегә йөкләнә.

8. Заявка 2023 елның 24 декабренә кадәр срокта «Яшүсмер» яшәү урыны буенча Я(Я)КҮ МАУда (Шамил Усманов проспекты, 51 йорт) кулга яки электрон рәвештә gudodpo@yandex.ru электрон почтасына бирелә.

## 7 бүлек. Судьялык

9. Турнир уеннарында судьялык түбәндәге составтагы судьялар коллегиясе тарафыннан гамәлгә ашырыла:

- баш судья Исаев С.В.;
- баш секретарь Морозова Н.И.

## 8 бүлек. Йомгак ясау

10. Командалар яулаган урыннарны билгеләү түбәндәге күрсәткечләр буенча гамәлгә ашырыла:

- иң күп җыелган очколар саны буенча;
- үзара уен буенча;
- иң күп җиңүләр саны буенча;
- кертелгән һәм кертелмәгән алкаларның аермасы буенча;
- иң күп кертелгән алкалар саны буенча;
- буллитлар буенча.

11. Әгәр күрсәткечләр ике һәм аннан күбрәк командаларда бертөрле булса, яуланган урыннар түбәндәге күрсәткечләр буенча билгеләнә:

- бу командалар арасында җыелган очколар саны буенча;
- бу командалар арасында җиңүләр саны буенча;
- бу командалар арасында иң күп кертелгән алкалар саны буенча.

12. Әгәр команда турнирның 50% календарь уеннарында уйнамаса, ул ярышлардан чыгарыла. Алдагы уеннарның нәтиҗәләре юкка чыгарыла.

13. Финал уеннарында командалар жирәбә буенча 2 төркемгә бүленә. Финал уеннарында урыннар билгеләү «стык» уеннарында билгеләнә.

14. Призлы урыннарны алган командалар кубоклар, медальләр, дипломнар һәм кыйммәтле призлар белән бүләкләнә.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клублары командалары арасында «Белые медведи» хоккей командасы тренеры Морозов О.Ю. истәлегенә багышланган «Белые медведи» клубы призына хоккей буенча XXIV турнир үткәрү турында нигезләмәгә кушымта

Яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клублары командалары арасында
«Белые медведи» хоккей командасы тренеры Морозов О.Ю. истәлегенә багышланган
«Белые медведи» клубы призына хоккей буенча XXIV турнирда катнашуга
«_________________» командасының заявкасы

| № | Фамилиясе, исеме | Туу датасы | Мәктәп, сыйныф | Өй адресы |
|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | |
| 2. | | | | |
| 3. | | | | |
| 4. | | | | |
| 5. | | | | |
| 6. | | | | |
| 7. | | | | |
| 8. | | | | |
| 9. | | | | |
| 10. | | | | |
| 11. | | | | |
| 12. | | | | |
| 13. | | | | |
| 14. | | | | |
| 15. | | | | |

______ уенчы кертелде
Җитәкче ______________________________ (Ф.И.А.и.)